# Тема: Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләрне кабатлау

Максаты: 1. Укучыларның иярченле кушма җөмләләр турындагы белемнәрен тирәнәйтү, аларда җөмлә төзелешенә һәм мәгънәсенә бәйле рәвештә тыныш билгеләрен дөрес куярга өйрәнү күнекмәләре формалаштыру.

2. Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр турындагы белемнәрне ныгыту, тиз фикерләү, төгәл җавап бирү, фикерләренең дөреслеген дәлилли белү, мөстәкыйльлек күнекмәләрен үстерү. БРТ га әзерлекне дәвам итү, өйрәнгәннәрне бер системага салу.

3. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

**Тезмә кушма җөмлә**

-Нинди җөмлә тезмә кушма җөмлә дип атала?

-Аның нинди төрләре бар?

-Тезмә кушма җөмләдә нинди бәйләүче чаралар катнаша?

-Тезмә кушма җөмләгә мисаллар

**Иярченле кушма җөмләләр**

-Нинди җөмлә иярченле кушма җөмлә дип атала?

-Төзелеше буенча аның нинди төрләре бар?

-Иярченле кушма җөмләдә нинди бәйләүче чаралар катнаша?

-Мәгънәсе буенча иярченле кушма җөмләнең нинди төрләре бар?

-Иярченле кушма җөмләгә мисаллар

2017
ГОД ЭКОЛОГИИ
В РОССИИ

1 . *Кояш кайчан нарат биеклеге булып күтәрелә, шул чакта Кама өсте чуп-чуар була.*

*2. Кайда урман киселә, шунда әллә никадәр үсемлек һәм хайван төре юкка чыга.*

*3. Һәр кеше урманның матурлыгына соклана.*

*4. Кошлар килгәнче, безнең сыерчык ояларыбыз биек киртәләргә кадаклап куелган була.*

5. *Агач үсмәгән урында дым булмый.*
6. *Хикмәт шунда: кешеләр табигатькә беркайчан да тиешенчә сак була алмадылар.*

1) Матур безнең авылларыбызның табигате. 2) Һәркайсы я инеш, я чишмә, я елга буена утырган. 3) Безнең бабаларыбыз тормыш тәҗрибәсен туплаган акыллы кешеләр булганнар. 4) Алар су-чишмәләрне күз карасыдай саклаганнар. 5) Күбесен хәтта изге чишмәләр дип йөрткәннәр. 6)Авырткан йөрәкләргә шифа, сагынган күңелләргә дәва булган чишмә суларын ничек изге дип әйтмәссең!..

7) Чишмәләр сере (...) халкыбыз тарихы бит ул. 8) Алар яшәсә, халкыбыз тормышындагы уңай традицияләр дә өзелмәс. 9) Шуңа күрә чишмә-күлләрне, буа-суларны карап, чистартып торыйк. 10) Аларның саф сулары тәнгә сихәт, җанга шифа булсын, алар турындагы җырлар ерак елларгача яңгырасын.

**Биреме:**

1. 1 җөмләдән рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне язып алыгыз.
2. 1-6 җөмләләрдән фразеологик әйтелмәне язып алыгыз.
3. 3 нче җөмләдә тартым белән төрләнгән ничә исем бар?
4. 7 нче җөмләдә күп нокталар урынына нинди тыныш билгесе куела?
5. 7-10 җөмләләрдән тезмә кушма җөмләнең номерын языгыз.

**Мөстәкыйль эшне тикшерү**

1. Табигате
2. Күз карасыдай
3. 2
4. Сызык
5. 10

**Бәяләү**

Хатасыз эш – “5”
1 хата - “4”
2 хата – “3”
3 хата – “2”

**Тестларны тикшерү**

1. а
2. б
3. в
4. б
5. б
6. б
7. а
8. б
9. б
10. б

**Бәяләү**

Хатасыз эш – “5”

1-3 хаталы эш – “4”

4-6 хаталы эш- “3”

7-10 хаталы эш – “2”

**Дәрес тәмам. Барыгызга зур рәхмәт!**